**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районының**
**«Югары Кәминкә авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлегенең**
**гражданнары җыены**
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районының Югары Кәминкә авыл җирлеге
составына керүче Ибрай Каргалы торак пунктында

**24 октябрь 2024 ел** **№ 4**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Югары Кәминкә авыл җирлегенең Ибрай Каргалы торак пунктында гражданнар җыены КАРАР КЫЛДЫ:

1. 2025 елда Югары Кәминкә авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә гражданнарның үзара салымын кертергә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүче гражданнардан, 1 төркем инвалидлардан, Луганск халык республикасы һәм Донецк халык республикасы махсус операциясендә булган затлардан тыш.

2. Алынган чараларны җибәрергә:

- **урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау** (Ибрай Каргалы торак пунктында урамнарны яктырту яктырткычларын монтажлау, ремонтлау, алмаштыру);
- Ибрай Каргалы торак пунктында **торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү** (юл кырыйларын чабу, бензин, триммер өчен запас частьләр сатып алу һәм хезмәт күрсәтүләргә түләү, юлларны грейдерлау, кышкы вакытта урамнарны кардан чистарту, ягулык майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, тракторчыга исәпләнгән хезмәт хакы), югарыда күрсәтелгән эшләрне башкару өчен кирәкле материаллар (хезмәт күрсәтүләр) сатып алу

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Югары Кәминкә авыл җирлегенең рәсми сайтында Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
ТР Чирмешән муниципаль районы
Югары Кәминкә авыл җирлеге башлыгы М.Н.Минһаҗев